КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 29 июль г.Казань № 631

Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерү эшчәнлеген оештыру турында

Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерү мәсьәләләрен хәл итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерүгә булышлык күрсәтүне оештыру буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәне;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерүгә булышлык күрсәтүне оештыру буенча ведомствоара эшче төркем составын;

Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия турындагы бертип нигезләмәне.

2. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерүгә булышлык күрсәтүне оештыру буенча ведомствоара эшче төркемгә иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерү чаралары планын эшләргә һәм расларга.

3. Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан

социальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзүне;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерү мәсьәләләрен хәл итү өчен муниципаль планнар эшләүне.

4. Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына үткәрелә торган эшне исәпкә алуны тәэмин итү максатларында «Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социализацияләү буенча республика регистры» мәгълүмат системасын эшләү һәм кулланышка кертү турындагы тәкъдимнәрне Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерүгә булышлык күрсәтүне оештыру буенча ведомствоара эшче төркемгә кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 29 июль, 631 нче карары белән расланды

Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерүгә булышлык күрсәтүне оештыру буенча ведомствоара эшче төркем
составы

| | |
|---|---|
| Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, эшче төркем җитәкчесе |
| Хәмәдишин Дәүфит Закир улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының хокук саклау һәм административ эшчәнлек буенча ярдәмчесе, эшче төркем җитәкчесе урынбасары |
| Абашев Әлмир Рәшид улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары |
| Бадриев Илдар Фоат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы |
| Гайнетдинов Азат Галимҗан улы | «Социаль тернәкләндерү һәм адаптация үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |
| Гобәйдуллин Әгъзам Самат улы | «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча) |
| Дәүлиев Рафаил Гани улы | Россия Федерациясе Җәзаларны үтәү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе каршындагы Җинаять-үтәү системасы эшчәнлеге мәсьәләләре буенча иҗтимагый совет рәисе (килешү буенча) |
| Долгов Марат Шамил улы | Татарстан Республикасы прокуроры урынбасары (килешү буенча) |
| Кадыйров Рөстәм Рәиф улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсе башлыгы |

| | |
|---|---|
| Ногманов Рафил Габтрәфикъ улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Сабурская Сария Харис кызы | Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча) |
| Таҗетдинова Клара Алексеевна | Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары. |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 29 июль, 631 нче карары белән расланды

# Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерүгә булышлык күрсәтүне оештыру буенча ведомствоара эшче төркем турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерүгә булышлык күрсәтүне оештыру буенча ведомствоара эшче төркем (алга таба – эшче төркем) күмәк орган булып тора, аның эшчәнлеге иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерүгә булышлык күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның үзара хезмәттәшлеген оештыруга юнәлдерелә.

1.2. Эшче төркемнең төп бурычы – иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларга җәмгыятькә реинтеграцияләнүдә, югалган туганлык һәм социаль элемтәләрне торгызуда, хезмәттә, көнкүрештә һәм башка адаптацияләнүдә булышлык күрсәтүне оештыру.

1.3. Эшче төркем үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук бу Нигезләмәгә таянып эш итә.

1.4. Эшче төркем эшчәнлеге яңадан социализацияләүгә булышлык күрсәтү күздә тотылган затларның ирекле булуы һәм ихтыярын белдерүе принципларына нигезләнә.

## II. Эшче төркем вәкаләтләре

2.1. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерү чараларын планлаштырганда һәм гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның үзара хезмәттәшлеген оештыру.

2.2. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерү чаралары составы буенча тәкъдимнәр һәм тәкъдимнамәләр әзерләү.

2.3. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерү буенча үткәрелгән чараларның нәтиҗәләрен һәм нәтиҗәлелеген анализлау һәм аларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү.

2.4. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерү чаралары планын эшләү һәм раслау.

## III. Эшче төркемне формалаштыру тәртибе

3.1. Эшче төркем Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан эшче төркем җитәкчесе, аның урынбасары һәм эшче төркем әгъзалары составында төзелә. Эшче төркем җитәкчесе – Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары.

3.2. Эшче төркем составына дәүләт хакимияте органнары вәкилләре, шулай ук килешү буенча «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе һәм оешмалар вәкилләре кертелә.

3.3. Эшче төркем эшчәнлегендә катнашу җәмәгать башлангычларында гамәлгә ашырыла.

3.4. Эшче төркем утырышларына дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, граждан җәмгыяте институтлары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре чакырылырга мөмкин.

## IV. Эшче төркем эшчәнлеген оештыру һәм аның эш тәртибе

4.1. Эшче төркем утырышлары кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә.

4.2. Эшче төркем утырышлары – эшче төркем җитәкчесе, ә ул булмаганда эшче төркем җитәкчесе урынбасары рәислегендә үткәрелә.

4.3. Эшче төркем утырышы, анда эшче төркем составының яртысыннан күбрәге катнашу шарты үтәлгәндә, тулы хокуклы була

4.4. Эшче төркем карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, тәкъдим итү характерына ия була һәм утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

4.5. Эшче төркем беркетмәләренең күчермәләре – эшче төркеме әгъзаларына, шулай ук, кирәк булганда, җибәрү исемлеге буенча җибәрелә.